*Хөрмәтле фәнни җитәкчем –*
*филология фәннәре докторы, профессор*
*Радик Гали улы Сибәгатовның*
*якты истәлегенә багышлана*

## Сүз башы

Ике бүлектән торган "Татар телендә сүзләр бәйләнеше сүзлеге" валентлык теориясенә нигезләнгән күчле сүз бәйләнешләрен үз эченә ала. Сүзләрнең лексик-грамматик мәгънәсе һәм грамматик формасы белән билгеләнүче валентлык теориясенең реальләшүе, ягъни сүзләрнең башка сүзләр белән бәйләнешкә керә алу сәләте беренче бүлектә төп юнәлештәге валентлы фигыльләрнең мәҗбүри актантлары белән бәйләнешендә тасвирлана.

Актантлар теге яки бу фигыль өчен мәҗбүри һәм факультатив (ирекле) була. Валентлы фигыльләр янында мәҗбүри актантларның кулланылмыйча калуы тулы булмаган җөмләләргә һәм сөйләм хаталарына китерергә мөмкин.

Сүзлекнең төп максаты – татар теле икенче тел буларак өйрәнелгән икетеллелек шартларында телне үзләштерүчеләрнең сөйләм үсешенә булышлык итү.

Сүзлекнең беренче бүлегендә төп юнәлештәге валентлы фигыльләрнең төрле формадагы сүзләр (актантлар) белән күчле синтаксик бәйләнешләре тасвирлана. Системалаштырылган мисаллардан күренүенчә, фигыль (иянең актант булып килүе исәпкә алынмады – сүзлектә сүзләр бәйләнешен тасвирлаганда төп берәмлек итеп сүзтезмәләр санала) үзе янында мәгънә тулылыгы өчен ике яисә өч актант белән бәйләнешне таләп итә. Кайбер очракта фигыль янында грамматик мәгънәләре охшаш яисә якын булган сүз формалары вариатив бәйләнештә (сүзлектә бәйләнешнең мондый төре // билгесе белән күрсәтелә) килергә мөмкин.

Сүзлек алфавитыбызда татар хәрефләренәң урынын үзгәрткәнче төзелгәнгә күрә, әлеге басмада фигыльләр элекке алфавит тәртибе буенча бирелә. Бу лингводидактик кулланмада һәр фигыльнең күчле бәйләнешен тәэмин итәрдәй актантларының грамматик формаларына аңлатма бирелә, структур типлары һәм курсив белән аларга мисаллар китерелә. Шулай ук сүзлектә фигыль белән рәвешләрнең янәшәлек юлы белән бәйләнеше дә кыскача характерлана.

Сүзлекнең беренче бүлегендә А – Р хәрефләренә башланучы 1181 фигыль тикшерелеп, аларның мәҗбүри актантлары белән бәйләнешләре тасвирлана, икенче бүлектә фигыль бәйләнешләренең дәвамы белән кушымта өлешендә исемнәрнең дә үз актантлары белән мөнәсәбәте сурәтләнә.

Сүзлек мәктәп укучыларына, студентлар, аспирантлар, укытучыларга практик кулланма буларак тәкъдим ителә.

## Шартлы кыскартылмалар

гади с. – гади сөйләм
жарг. – жаргон
зат-сыз – затланышсыз
$И_1$ – баш килештәге исем
$И_2$ – иялек килешендәге исем
$И_3$ – юнәлеш килешендәге исем
$И_4$ – төшем килешендәге исем
$И_5$ – чыгыш килешендәге исем
$И_6$ – урын-вакыт килешендәге исем
ирон. – ироник мәгънәдә
ис. – исем
иск. – искергән сүз
к. – кара
кимс. – кимсетеп әйтү
кит. – китап теле
күч. – күчерелмә мәгънәдә
лингв. – лингвистика термины
мат. – математика термины
махс. – махсус термин
мед. – медицина термины
сир. – сирәк кулланылышта
сөйл. – сөйләм телендә
тар. – тарихи
тех. – техника термины
ф. һәм Ф – фигыль
$Ф_{инф.}$ – инфинитив формасындагы фигыль
шелт. – шелтәләү сүзе
шигъ. – шигъри сөйләмдә
этн. – этнография
юр. – юридик термин